РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АМЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Яңа Әмзә ав. КАРАР

«12» ноябрь 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Назначить на 13 часов 00 минут 4 декабря 2021 года около здания Старо-Амзинской СДК по адресу: д.Старая Татарская Амзя, ул. К.Маркса, д.29 сход граждан д.Старая Русская Амзя Нурлатского района Республики Татарстан по вопросу введения самообложения в д. Старая Русская Амзя Амзинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан 2021 елның 4 декабрендә 13 сәгать 00 минутка Иске Татар Әмзәсе авылы, К. Маркс ур., 29 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Татар Әмзәсе авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зират тирәсен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында

http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Рус Әмзәсе авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы                А.Ә. Насыйбуллин